Муниципаль тур

Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2024-2025 нче уку елы
4 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 120 минут
Максималь балл – 50

I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Саңгырау тартыклардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) килгән
2) пычак
3) зарар
4) кызыл

2. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) унбишләп
2) сулык
3) хәбәр
4) яфраклы

3. *Ялкын* сүзендә я хәрефе нинди аваз белдерүен билгеләгез. **(2 балл)**
1) [а] авазын
2) [йә] авазын
3) [йа] авазын
4) [ә] авазын

4. Хаталы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) алма
2) яңгыр
3) хөнәр
4) чәүкә

5. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
Куе йонлы, күшәүче, куштояклы вак йорт хайваны
1) сыер
2) сарык
3) ат
4) үгез

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**

Җайлы сүз

1) кыска сүз.
2) еракка илтә.
3) минем сүз.
4) җан эретә.

7. Антоним сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**

1) төз, туры
2) эшләү, ашау
3) сөйләшү, йоклау
4) яшь, карт

8. *Бор* сүзенә тамырдаш булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

1) бора
2) борыч
3) боргыч
4) борды

9. Иялек килеше кушымчасы кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

1) кызга әйтү
2) апаны көтү
3) укучының дәфтәре
4) авылда яшәү

II. Теоретик бирем.

Синонимнар турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез.

(5 балл)

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А) кул арасына керү	1) сөйләргә теләү
Ә) тел кычыту	2) кузгалу
Б) хәрәкәткә килү	3) карау
В) тел бистәсе	4) күп сөйләүче
Г) күз төшерү	5) булышу

Җавап : _____

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Беркөнне мин Аккүлгә киттем. Тын гына (утырган / барган / яткан) көзге күл өстенә ялтырап юл салынган. Күлнең бер читендә кыр казлары әрле-бирле (утыралар / йөриләр / шаяралар).

Камышларны ике якка аерып, суга (бардым /кердем / чыктым). Анда, сыңар канаты белән талпынып, бер кыр казы очарга маташа, (бәлки / ләкин / гаять) оча алмый, туктый. Мин аны җиңел генә тотып, өйгә алып кайттым. (*Г. Ахунов*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Әти гармун уйный өйдә,
Бармаклар йөг...реп тора.
Күпме к...йләр белә бит ул,
Би...рәкләр дә булдыра.
Әти уйный, ә мин биим,
Курчаклар карап т...ра. (*Т. Галимуллина*)

3. Шигырьдән *әни* сүзенең антонимын күчереп языгыз. **(2 балл)**

_____

4. *Күпме* сүзенә аваз-хәреф анализы ясагыз. **(5 балл)**

5. “Кышкы урманда” темасына 6-7 җөмләдән торган инша языгыз. (**7 балл**)

Муниципаль тур

Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2024-2025 нче уку елы
5 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 120 минут
Максималь балл – 54

I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Яңгырау тартыклардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) күркәм
2) поши
3) халәт
4) гараж

2. Рәт гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) бертуган
2) төнбоек
3) көндезге
4) зәңгәрсу

3. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
Акбәкәл болын буйлап чабып китә. (Ф.Яруллин)
1) чабып
2) буйлап
3) болын
4) китә

4. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) түгел
2) өстәл
3) рәссам
4) кайткач

5. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
чыпчыксыманнар отрядыннан кечерәк кенә чуар сайрар кош
1) карга
2) песнәк
3) күгәрчен
4) сандугач

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
Бергә эшләсәң,
1) юл уңар.
2) тиз бетәр.
3) тиз ял итәрсең.
4) авыр эш тә жиңел.

7. Җөмләдәге фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
Аның эшенә аяк салучылар шактый булды.
1) булышучылар
2) комачаулаучылар
3) хуплаучылар
4) ярдәм итүчеләр

8. Тамыр сүз күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) каенлык
2) өчпочмак
3) ир-ат
4) әниләрне

9. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә каравын билгеләгез. **(2 балл)**
*Бакчадагы агачлар күптән **яфракларын** койганнар. (Д. Аппакова)*
1) исем
2) сан
3) сыйфат
4) фигыль

10. Җөмләдәге аергычны билгеләгез. **(2 балл)**
Мин курчагымның күлмәген юдым.
1) мин
2) курчагымның
3) күлмәген
4) юдым

II. Теоретик бирем.

Омонимнар турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез.

(5 балл)

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А) су кебек эчү	1) тыңлау
Ә) колак салу	2) белмәү
Б) авызга су кабу	3) эшсез йөрү
В) сай йөзү	4) дәшмәү
Г) трай тибү	5) яхшы белү

Җавап : _____

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Нәсимә аны юкка гына "Йолдызкаем" дип (кушмый / йөрми / сөйләми) шул. Песинең йоннары чем-кара, ә маңгаенда, нәкъ ике колак уртасында ап-ак табы бар. Йолдыз кебек (әйтеп / кычкырып / янып) тора. Алар көндезләрен бергә-бергә (җитәкләшеп / сөйләшеп / чабышып) уйныйлар. Кич җиткәч, песи Нәсимәнең юрган астына керә дә, мырр-мырр итеп, йомшак кына (көйли / йоклый / елый) башлый. Әйтерсең, ул шулай ягымлы җыры белән дустын йоклата. (*Ә. Бикчәнтәевадан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Кемнең кигән киемнәре
Энҗе кар бөрт...кләре?
Кемнең көм...ш күк сакалы,
Чәчләре, кер...екләре?
Кем соң безгә шундый ...мьле
Яңа ел алып килә?
Матур-матур капчыкларга
Күчтәнәч салып килә? (*Ж. Тәрҗеманов*)

3. Шигырьдән *ак* сүзенең синонимын күчереп языгыз, ни өчен әлеге сүз белән бирелгәнен аңлатыгыз. **(4 балл)**

4. *Капчыкларга* сүзен мәгънәви кисәкләргә таркатыгыз, нинди сүз төркеменә каравын, төрләнешен билгеләгез. **(4 балл)**

5. "Минем дустым" темасына 7-8 җөмләдән торган инша языгыз. (**8 балл**)

Муниципаль тур

Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2024-2025 нче уку елы
6 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 150 минут
Максималь балл – 60

I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Тел алды тартыгын билгеләгез. **(2 балл)**
1) [з]
2) [к]
3) [h]
4) [м]

2. [ō] авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) колын
2) вагон
3) олан
4) торак

3. Нечкә сузыклардан гына торган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Әдәп башы — тел.
2) Инсафлының теле саф.
3) Тел күңелнең көзгесе.
4) Татлы тел тимер капканы ачар.

4. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) эчтәлек
2) ничек
3) безнең
4) китапта

5. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
Ябыну өчен ике тукыма арасына мамык яки шуңа охшаш нәрсә куеп, сырып ясалган урын-җир.
1) юрган
2) мендәр
3) киез
4) палас

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
Бауның озыны,

1) сүзнең кыскасы яхшы.
2) эшнең кыскасы яхшы.
3) сүзнең дә озыны яхшы.
4) эшнең дә күплеге яхшы.

7. Җөмләдәге фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
Скрипкә тавышы килгән якка колагын салып бераз уйланып утырды. (Г. Бәширов)
1) куркып
2) тыңлап
3) уйланып
4) тырышып

8. Җөмләдәге омонимның төрен билгеләгез. **(2 балл)**
Печән чабарга чык,
Кибеп беткәнче чык.
1) саф
2) омоформа
3) омографлар
4) омофон

9. Җөмләдәге алмашлыкның төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**
Бик сагындым синең шифалы суларыңны. (Ф.Шәфигуллин)
1) күрсәтү
2) зат
3) билгеләү
4) юклык

10. Җөмләдә рәвешнең нинди җөмлә кисәге булуын билгеләгез. **(2 балл)**
Әниемнең көмештәй чәчләрен яратам.
1) аергыч
2) хәл
3) хәбәр
4) тәмамлык

II. Теоретик бирем.

Иҗек турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**7 балл**)

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүз һәм аның ясалышын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А) көнбагыш	1) тамыр сүз
Ә) пыяла	2) ясалма сүз
Б) сиртмә койрык	3) саф кушма сүз
В) ямьле	4) тезмә сүз
Г) әйләп-бәйләп	5) парлы

Җавап : _____

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Биологиядән "икеле" алуына һич тә үкенмәде Камил. Чөнки бу фәнне ул башкаларга караганда яхшырак белә. "Икеле" алуының сәбәбе дә көлке сыман: контроль эш дәфтәрен тапшырмаган. Эшен беренче булып (эшләгән / төгәлләгән / биргән) иде дә, янәшә партада утыручы Сәриянең (эшен / биремен / мисалын) эшли алмаганын күреп, укытучы сизмәгәндә генә, дәфтәрен аңа сузды. Дәрес бетеп, тәнәфескә кыңгырау шылтырагач, укытучы үзе (әйтеп / карап / йөреп) җыйды дәфтәрләрне. Минем дәфтәр Сәриядә дип (сөйләмәс / дәшмәс / әйтмәс) бит инде! (Д. *Гайнетдиновадан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)** Һәр җавапка 0,5 балл.

Яңа ел җитте! Яңа ел!
Кышы, Язы, Җә..., К...зе –
Бар...сы белән дә яңа ул.
Ә иске ел ерак китте.
Киткән чакта елап китте.
Ул соң ниләр алып китте,
Һәм н...ләр калдырып китте? (*Р. Гаташ*)

3. Шигырьдән антоним исем һәм сыйфатларны парлап күчереп алыгыз, сүз төркемнәрен күрсәтегез. **(6 балл)**

_____
_____
_____

4.*Кыш* сүзенә 3тамырдаш сүз уйлап языгыз. **(6 балл)**

5. “Тиздән Яңа ел” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

Муниципаль тур

Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2024-2025 нче уку елы
7 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 150 минут
Максималь балл – 60

I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

Төркем булып йөзгән авыр болытлар бертуктаусыз куера бара.(А.Расих)

1) төркем
2) йөзгән
3) бертуктаусыз
4) куера

2. Күпнокталар урынына ъ билгесе язылырга тиеш сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

1) Вил...дан
2) гам...сез
3) ел...язма
4) мәкал...

3. *Кайнар* сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

1) кайнар су
2) кайнар чәй
3) кайнар сөт
4) кайнар дулкын

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

Баш астына салу өчен, мамык, йон тутырып эшләнгән йомшак әйбер

1) юрган
2) мендәр
3) япма
4) җәймә

5. Җөмләдәге фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**

Марат күршесенең күзенә төтен җибәргән.

1) ком сибү
2) кыйнау
3) ялганлау
4) үпкәләтү

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
Туры әйткән - котылган, ...
1) морадына ирешкән.
2) үз эшләрен эшләгән.
3) ялганлаган - тотылган.
4) ялган әйткән - йомшак сөягән.

7. Җөмләдәге эндәш сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
Рәхмәт сиңа җылы назың өчен, Татлы сүзең өчен, әнием.
1) рәхмәт
2) сиңа
3) әнием
4) җылы назың өчен

8. Мәкальдәге фигыльнең төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**
Бәхетне юлдан эзләмә, белемнән эзлә.
1) сыйфат фигыль
2) боерык фигыль
3) хикәя фигыль
4) шарт фигыль

9. Җөмләдә куелырга тиешле тыныш билгесен билгеләгез. **(2 балл)**
Ризык иң кадерле нәрсә.
1) өтер
2) ике нокта
3) сызык
4) нокталы өтер

10. Җөмләдә рәвешнең нинди җөмлә кисәге булуын билгеләгез. **(2 балл)**
Әниемнең көмештәй чәчләрен яратам.
1) аергыч
2) хәл
3) хәбәр
4) тәмамлык

II. Теоретик бирем.

Сүзтезмә турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(8 балл)**

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүз һәм андагы басымның урынын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А) шатлыклы	1) беренче иҗектә
Ә) карамастан	2) икенче иҗектә
Б) кемдер	3) өченче иҗектә
В) бакчачылык	4) дүртенче иҗектә
Г) әбиләребез	5) бишенче иҗектә

Җавап : _____

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Май-матур (килергә тырыша / аяк басты / юлга чыкты) туган ягыма!

Майсыз кар бетми, дигән сүзне дөресләгәндәй, урмандагы коры елга төбендә дә карның эзе калмады. Җирне сусыл яшь үлән, агачларны озын һәм кызгылт песиләр, яшел яфраклар каплады. Хәзер кая карама, шунда (кар / чәчәк / яфрак). Табигать нинди (матур / саф / иркен) сулый! Хәтта сылу каеннар да (салкынча / җылымса / кызу) матур көннәр җитүенә чынлап ышанды, җилемле һәм хуш исле яфрагын ача башлады. *(Г. Хәсәнов)*

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Һичкайсыгыз таныш түгел хәсрәт берлә,
Утыргансыз матур гына, рәт-рәт берлә;
Кышкы кичнең оз...нлыгын сизмисез дә
Ә...кәгезнең сөйләгәне әкият берлә.

Тышта и...сен ачы җилләр, ту...сын карлар,
Өй түбәсе саламнары килсен тар-мар,
Суыклыктан очар кошлар оча алмасын,—
Сезнең урын җылы, әйбәт,— ни кайгы бар? (*Г. Тукай*)

3. *Тышта и...сен ачы җилләр, ту...сын карлар, Өй түбәсе саламнары килсен тар-мар* шигъри юлларыннан аергычларны аерылмышлары белән күчереп языгыз. (**2 балл**)

_____

4. Шигырьдән искергән сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)

_____

5. *Оз...нлыгын* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ языгыз. **(4 балл)**

_____
_____
_____
_____
_____

6. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне күчереп алыгыз. **(2 балл)**

_____

7. "Яраткан һөнәрем" темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**9 балл**)

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

Муниципаль тур

Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2024-2025 нче уку елы
8 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 150 минут
Максималь балл – 60

I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Җөмләдәге кече тел охшашлануы күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
Тузанга ялан тәпиләре белән лап-лоп басып, иркенләп атлый балалар (Р.Фәизов)
1) тузанга
2) тәпиләре
3) иркенләп
4) балалар

2. Әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) умарта
2) чордаш
3) гарәпчә
4) шифалы

3. *Кояш - көне, ай төнне яктыртыр* мәкалендә кулланылган сүзләрнең төрен билгеләгез. (**2 балл**)
1) капма-каршы мәгънәле сүзләр
2) мәгънәдәш сүзләр
3) аваздаш сүзләр
4) тамырдаш сүзләр

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
Бүлмәнең берәр почмагын каплау яки аеру өчен эленгән тукыма
1) штора
2) челтәр
3) чыбылдык
4) чаршау

5. Җөмләдәге алынма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

Композитор киселгән агачларга карамаска тырышты аңа алар ыңгырашып яталар кебек тоелды.
1) композитор
2) агачларга
3) алар
4) ыңгырашып

6. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
Эчне мәче тырнау -
1) көлү
2) ябыгу
3) уйлану
4) тамак ачу

7. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатлар булган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
Кинәт мәче башлы ябалак ук кебек аска томырыла. (М.Закиров)
1) әллә кайда, һичкайда
2) яшькелт, карасу
3) сап-сары, җете кызыл
4) бөтен, һәммә

8. Хәзерге заман хикәя фигыль кулланылган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
Кинәт каядыр колагына серле аваз чалынгандай булды. (Р.Мөхәммәдиев)
1) Минем киләсемне алдан әйтеп куйган булганнар.
2) Бүлмәдәгеләрнең берсе дә бу турыда сөйләшми.
3) Хәзер җыр башланачак.
4) Кояш, күк читеннән үрмәләп, югары күтәрелә башлады.

9. Аерымланган хәлнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
Мин, кабаланып, кармак сабына тотындым. (И. Гарифуллин)
1) максат хәле
2) шарт хәле
3) сәбәп хәле
4) рәвеш хәле

10. Җөмләдәге нокталар урынына тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**
Эре сипкелләр төшкән аксыл чырайлы битләренә <...> ак күлмәкләренә, панамкаларына да соргылт тузан кунды инде.
Җавап: _____

II. Теоретик бирем.

Сыйфат сүз төркеме турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(8 балл)**

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүзләрне һәм хәрефләрне тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А) са...	1) э
Ә) а...ыл	2) у
Б) тә...бә	3) ү
В) мәс...әлә	4) ь
Г) тә...минат	5) в

Җавап : _____

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Көньяктан кошлар агыла. Дымга (боеккан / тиенгән /сусаган) чиксез болыннар, пар бөркеп яткан кырлар, агачта кызгылт бөреләр – һәммәсе бер-бер артлы (ата / ачыла / эри). Авыл янындагы коры елгада кар ята, ә урманда тәүге чәчәкләр күренә.

Урманда имәннән (соң / битәр / кала) барлык агачлар ямь-яшел. Имәннәр шәп-шәрә, (чөнки / имеш / әллә) алар суыктан куркалар. Язгы суыклар кире кайтмагае дип, киң кырлы зур-зур яфракларын, мүк кебек яшькелт сыргаларын ачмыйлар. Имәннәр белә: шушы вакытта һәр елны (ак / өшеткеч / салкынча) кырау төшә. (*Г. Хәсәнов*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) Һәр җавапка - 0,5 балл.**

Тау итәген томан сарган чакта
Җыр яңгыраса кичке тын...ыкта,
Таулар аша юллар узган якта
Сагынучың барын он...тма!
Эсселектән арып, хәлдән та...п,
Ятып калсаң кайнар ком...ыкта,
Сусавыңны басар чык булырдай
Якын дустың барын онытма! (*К. Булатова*)

3. Икенче куплеттан фразеологик әйтелмәне күчереп языгыз. (**2 балл**)

_____

4. *Эсселектән* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**4 балл**)

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

5. *Җыр* сүзенә 2 тамырдаш сүз уйлап языгыз. **(2 балл)**

_____

6. *Кызу* сүзенең синонимын күчереп языгыз. **(2 балл)**

_____

7.“*Йолдызларда – галәм сере*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(10 балл)**

Муниципаль тур

Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2024-2025 нче уку елы
9 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 180 минут
Максималь балл – 64

I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. *...лак, ...рак, ...рганак* сүзләрендә күп нокталар урынына язылырга тиешле хәрефләрне билгеләгез. **(2 балл)**
1) е
2) йы
3) йе
4) җ

2. Туры мәгънәсендә кулланылган сыйфатны билгеләгез. **2 балл)**
1) ак бәхет
2) каты холык
3) кара көн
4) зәңгәр күк

3. Морфологик принципка буйсынып язылган очракны билгеләгез. **(2 балл)**
1) унбиш
2) компьютер
3) баерак
4) мөстәкыйль

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
Махсус сугылган яки кисеп тегелгән, озынча тукыма кисәге
1) күлмәк
2) чүпрәк
3) юрган
4) сөлге

5. Түбәндәге җөмләдә аерымланган хәлнең төрен күрсәтегез:
Күпме генә хәтерләргә тырышса да, Ярмөхәммәт чәчкә-кызның кемгә охшаганлыгын исенә төшерә алмады. (Р. Батулла)

1) кире хәл
2) урын хәле
3) вакыт хәле
4) рәвеш хәле

6. Тамырдаш сүзләр бирелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) бозваткыч, бозлавык
2) язгы, язмача
3) барлык, бару
4) сынык, сыкы

7. II зат берлек сандагы тартым белән төрләнгән урын-вакыт килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**
1) урманнарыңның
2) китабымда
3) җаныңда
4) мәгънәсен

8. Җөмләдәге фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
Әмирнең эшләгәнен карап тору күңелле, чөнки аның кулы кулга йокмый..
1) кире
2) уңган
3) ялкау
4) әкрен

9. *Их, тагын бер мәртәбә күрәсе иде ул шәһәрне!* җөмләсендәге *их* сүзенең нинди сүз төркеменә каравын билгеләгез. **(2 балл)**
Җавап: _____

10. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
Шунда өлкән абыстай лып итеп килеп утырды, икенчесе аны күтәреп бастырырга кереште. (М. Хөсәен)
Җавап: _____

II. Теоретик бирем.

Иярченле кушма җөмлә турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(8 балл)**

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Мәкальләрнең өлешләрен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А	Яхшылык өеп куелмый,	1	яманлык булып кайта.
Ә	Кайчагында изгелек	2	күңелең ачылыр.
Б	Усаллык җиңмәс,	3	турылык җиңәр.
В	Яхшы белән сөйләшсәң,	4	яманлык җиргә куелмый.

Җавап : _____

IV. Гамәли-ижади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Иртәгә Сабан туе дигән кичне кем генә тыныч йоклый алды икән! Инде күзләрең дә (изрәп / йомылып / ачылып), йоклап та барасың. Юк, кая ул! Йоклыйм гына дигәндә, күрше малайларның Сабан туена дип тектергән яңа күлмәкләре, камзуллары, йә булмаса, яңа кәләпүшләре күз алдына килә. Сузылып кына үзеңнең баш очына әзерләп куйган киемнәреңне (капшап / карап / күзләп) карыйсың да авыр сулап куясың.

... Иртә белән шыгырдап ишек ачылган тавышка уяндым. Кичтән таң белән тормакчы булып ятсам да, (нинһаять / әмма / барыбер) соңга калганмын. Ник дисәң, әле яктыра гына башлаган. Бүген юри ут кабызмыйлар дип уйладым, чөнки әгәр лампа яндырсаң, Сабан туе иртәләрендә генә була торган бу үз алдына бер моңсу, соры тынлык юкка чыгар да, бәйрәм куанычының кайсы ягыдыр (алда / китек / сыңар) булыр кебек иде... (*Г. Бәшировтан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) Һәр җавапка - 0,5 балл.**

Дустым

Бер дустым бар. Аның белән
Күпме гом...р узылган.
Ул дустымның исеме <....> юл
Чиксезлеккә сузылган.
К...дерле ул картка, яшькә -
Чын дуслыкка ни җитсен!
Кайчак дөнья йөз чө...рә
Ә син аңа х...җәтсең. (*Р. Вәлиев*)

3. Шигырьнең беренче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

_____

4. Шигырьдән антоним сүзләрне күчереп языгыз. (**2 балл**)

_____

_____

5. Шигырьдән ясалма сыйфатны күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**4 балл**)

_____

_____

_____

_____

6. Шигырьнең икенче куплетыннан фразеологик әйтелмәне күчереп языгыз, сүз төркемен билгеләгез. **(2 балл)**

_____

_____

7. Шигырьнең икенче куплетыннан тойгылы җөмләне күчереп языгыз. **(5 балл)**

8.“*Матурлыкны үзебез тудырабыз*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

Муниципаль тур

Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2024-2025 нче уку елы
10 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 180 минут
Максималь балл – 64

I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Алынма сүзнең дөрес язылган очрагын билгеләгез. **(2 балл)**
1) автономияның
2) автономиянең
3) автономиенең
4) автономиеның

2. Гарәп теленнән кергән алынма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
арка
канат
оешма
кыяфәт

3. *Бүре* сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган җөмләне күрсәтегез. **(2 балл)**
1) Авылда Бүре Вәлиләр нәселен читләтеп узалар иде.
2) Бүре – зур эткә охшаган имезүче ерткыч хайван.
3) Мәхмүт картның башында бүре тиресеннән тегелгән зур бүрек иде.
4) Кыш җитсә, авылга бүреләр килеп интектерә иде.

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
өйнең, бүлмәнең ишеккә каршы ягы
1) ишек
2) түр
3) өйалды
4) өстәл

5. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең нинди сүз төркеменә каравын билгеләгез. **(2 балл)**
Сукмакка иелеп, ***зәмһәрир*** *суыкларда сынып төшкән ботакны алам. (Р.Рахман)*
1) исем

2) фигыль
3) сыйфат
4) рәвеш

6. Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Ә мин бу көнне бик кыю идем.
2) Инде мин җитдиләндем.
3) Мин үземне чын солдат итеп әнә шул очрашуда тойдым.
4) Очраклы рәвештә генә юлыма тап булган бу абзый миңа «яшәү мәгънәсе», «иманлылык» төшенчәләрен аңлатып киткән иде.

7. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге булуын билгеләгез. **(2 балл)**
Дала кылганнарын, елга ярындагы талларны тарап, ***коры*** *җилләр исә. (Г.Афзал)*
1) вакыт хәле
2) аергыч
3) туры тәмамлык
4) урын хәле

8. Бәйлек ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**
1) китап белән ике
2) ефәк кулъяулык
3) татарча спектакль
4) урамнан керү

9. *Мәһабәт тел тирәге < ... > милләтнең яшәү терәге!* (М. Галиев) җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. **(2 балл)**
Җавап: _____

10. Хәл фигыльне күчереп языгыз: *баргансың, укыйсы, көлеп, сөйләшү* **(2 балл)**
Җавап: _____

II. Теоретик бирем.

Тезмә кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. (**8 балл**)

_____
_____
_____
_____

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Алмашлык һәм аның төркемчәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А) бу	1) сорау алмашлыгы
Б) бөтен	2) билгеләү алмашлыгы
В) кайсы	3) зат алмашлыгы
Г) ул	4) юклык алмашлыгы
Д) һичнәрсә	5) күрсәтү алмашлыгы

Җавап : _____

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Урман хәрәкәтсез һәм тып-тын. Кояш чыккан вакыт. (Мәһабәт / мәхәбәт / мәхәббәт) төз наратларның очлары җылы нурга манчылып, рәхәт бер (талгынныкка / талгынлыкка / талгыныкка) бирелгәндәй, шылт та итмичә, тик кенә торалар... Берәм-сәрәм очраган усакларның (көмеш / көмөш / кемеш) яфраклары, таң сулышыннан уянышып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле, җилфердәшәләр... Ачык урыннарда, җиргә таба сыгыла төшеп, хәрәкәтсез ак томан ята. Үлән эченнән узсаң, шунда ук итекләрнең йөзләре ялтырап чыга, яшькелт-кара тасмадай эзләр артта сузылып кала. Үсемлекләрнең исле пары борынны кытыклый һәм үпкәләргә (сыланган / сыланган / сылынган) кебек була. Озак килүгә дә йөкнең авырлыгына да карамастан, тән ниндидер җиңеллек, күңел исә шул җиңеллектән (гәмсез / гамьсез / гамъсез) бер рәхәтлек тоя... (*Ә. Еники*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) Һәр җавапка - 0,5 балл.**

Шигырь

Тып-тын торам, чакырмыйм да инде,
Эзләмим дә җу...ган сүземне.
Чакырмыйча килгән күз яшедәй
Килсен миңа бүген ул үзе.

Көтмәгәндә килсен күңелемә,
Һәм кәгаз...гә төшсен соң...ннан.
Сө...ндереп <....> ишек шакымыйча,
Килеп кергән якын дус сыман. (*Р. Вәлиев*)

3. Шигырьнең икенче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

_____

4. Шигырьнең икенче куплетыннан гарәп-фарсы алынмаларын күчереп языгыз. (**3 балл**)

_____

5. *Эзләмим* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

6. Шигырьдән *кебек* бәйлегенең синонимын күчереп языгыз. **(2 балл)**

_____

7. Шигырьдән артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны күчереп языгыз. **(2 балл)**

_____

8.“*Яшәү яме*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(10 балл)**

Муниципаль тур

Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2024-2025 нче уку елы
10 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 180 минут
Максималь балл – 64

I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Алынма сүзнең дөрес язылган очрагын билгеләгез. **(2 балл)**
1) автономияның
2) автономиянең
3) автономиенең
4) автономиеның

2. Гарәп теленнән кергән алынма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
арка
канат
оешма
кыяфәт

3. *Бүре* сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган җөмләне күрсәтегез. **(2 балл)**
1) Авылда Бүре Вәлиләр нәселен читләтеп узалар иде.
2) Бүре – зур эткә охшаган имезүче ерткыч хайван.
3) Мәхмүт картның башында бүре тиресеннән тегелгән зур бүрек иде.
4) Кыш җитсә, авылга бүреләр килеп интектерә иде.

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
өйнең, бүлмәнең ишеккә каршы ягы
1) ишек
2) түр
3) өйалды
4) өстәл

5. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең нинди сүз төркеменә каравын билгеләгез. **(2 балл)**
Сукмакка иелеп, ***зәмһәрир*** *суыкларда сынып төшкән ботакны алам. (Р.Рахман)*
1) исем

2) фигыль
3) сыйфат
4) рәвеш

6. Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Ә мин бу көнне бик кыю идем.
2) Инде мин җитдиләндем.
3) Мин үземне чын солдат итеп әнә шул очрашуда тойдым.
4) Очраклы рәвештә генә юлыма тап булган бу абзый миңа «яшәү мәгънәсе», «иманлылык» төшенчәләрен аңлатып киткән иде.

7. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге булуын билгеләгез. **(2 балл)**
Дала кылганнарын, елга ярындагы талларны тарап, ***коры*** *җилләр исә. (Г.Афзал)*
1) вакыт хәле
2) аергыч
3) туры тәмамлык
4) урын хәле

8. Бәйлек ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**
1) китап белән ике
2) ефәк кулъяулык
3) татарча спектакль
4) урамнан керү

9. *Мәһабәт тел тирәге < ... > милләтнең яшәү терәге!* (М. Галиев) җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. **(2 балл)**
Җавап: _____

10. Хәл фигыльне күчереп языгыз: *баргансың, укыйсы, көлеп, сөйләшү* **(2 балл)**
Җавап: _____

II. Теоретик бирем.

Тезмә кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. (**8 балл**)

_____
_____
_____
_____

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Алмашлык һәм аның төркемчәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А) бу	1) сорау алмашлыгы
Б) бөтен	2) билгеләү алмашлыгы
В) кайсы	3) зат алмашлыгы
Г) ул	4) юклык алмашлыгы
Д) һичнәрсә	5) күрсәтү алмашлыгы

Җавап : _____

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Урман хәрәкәтсез һәм тып-тын. Кояш чыккан вакыт. (Мәһабәт / мәхәбәт / мәхәббәт) төз наратларның очлары җылы нурга манчылып, рәхәт бер (талгынныкка / талгынлыкка / талгыныкка) бирелгәндәй, шылт та итмичә, тик кенә торалар... Берәм-сәрәм очраган усакларның (көмеш / көмөш / кемеш) яфраклары, таң сулышыннан уянышып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле, җилфердәшәләр... Ачык урыннарда, җиргә таба сыгыла төшеп, хәрәкәтсез ак томан ята. Үлән эченнән узсаң, шунда ук итекләрнең йөзләре ялтырап чыга, яшькелт-кара тасмадай эзләр артта сузылып кала. Үсемлекләрнең исле пары борынны кытыклый һәм үпкәләргә (сыланган / сыланган / сылынган) кебек була. Озак килүгә дә йөкнең авырлыгына да карамастан, тән ниндидер җиңеллек, күңел исә шул җиңеллектән (гәмсез / гамьсез / гамъсез) бер рәхәтлек тоя... (*Ә. Еники*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) Һәр җавапка - 0,5 балл.**

Шигырь

Тып-тын торам, чакырмыйм да инде,
Эзләмим дә җу...ган сүземне.
Чакырмыйча килгән күз яшедәй
Килсен миңа бүген ул үзе.

Көтмәгәндә килсен күңелемә,
Һәм кәгаз...гә төшсен соң...ннан.
Сө...ндереп <....> ишек шакымыйча,
Килеп кергән якын дус сыман. (*Р. Вәлиев*)

3. Шигырьнең икенче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

_____

4. Шигырьнең икенче куплетыннан гарәп-фарсы алынмаларын күчереп языгыз. (**3 балл**)

_____

5. *Эзләмим* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

6. Шигырьдән *кебек* бәйлегенең синонимын күчереп языгыз. **(2 балл)**

_____

7. Шигырьдән артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны күчереп языгыз. **(2 балл)**

_____

8.“*Яшәү яме*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

Муниципаль тур

Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2024-2025 нче уку елы
11 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 180 минут
Максималь балл – 64

I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Татар теленең орфографик нормаларына туры килмәгән сүз язылган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Элек бакчага Ләйсән әтисенә, йә әнисенә ияреп килә иде.
2) Дустым Расихның сүзләре дөрескә чыкты.
3) Бүген бик күп халыкларның әдәбияте белән танышмын.
4) Октябрь аеның урталары җитеп килгән чак иде.

2. Сөйләм сафлыгына зыян китерә торган сүз кулланылган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Безнең мәктәп ярышта беренчелекне алды.
2) Башка җирдә әле кыяр чәчәк атарга да өлгермәгән.
3) Маладис, безнең кеше икәнсең! - дип, аркасыннан кагып куйды.
4) Кыз, күлмәк итәкләрен җыйнап, идән юарга тотынды.

3. Фразеологизм дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) чәчләр үрә тору
2) чәчләр юешләнү
3) чәчне үрү
4) чәчне юу
4) яш...лек

4. Бәйлек ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**
1) түгәрәк алан
2) әнидән сорау
3) авыл аша үтү
4) җәйгәчә эшләү

5. Барлыкта, билгелесез үткән заманда, төп юнәлештәге хикәя фигыль кулланылган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

1) Алар Мәскәүгә кадәр поезд белән үз ирекләрендә барачаклар.
2) Аю мескен куянны тиргәгән дә киткән, ә куян башкаларны көткән.
3) Эшен тәмамлап өлгермәде, күктән гаҗәеп яңгыр сибәли башлады.
4) Кинәт шул туп уйнаучыларның кулыннан ычкынып китте һәм тәгәрәп килеп бала каршында туктады.

6. Аерымланган кире хәл кулланылган җөмләне күрсәтегез (тыныш билгеләре куелмаган). **(2 балл)**
1) Шул әманәтне алып кайту өчен бистәдән калага килгәннәр иде.
2) Без бит монда хушлашыр өчен килдек.
3) Вакыт-вакыт ярсып китүенә карамастан мин аны ничек тә дөрес гадел аңларга тырышам.
4) Классларына кереп утыргач ул дәфтәрен читкә этәрде.

7. Бирелгән җөмләдәге иярчен компонентның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

Тагын шунысы бар: тау эчендә авыл була алмый. (Галимҗан Гыйльманов)
1) аналитик иярчен ия җөмлә
2) аналитик иярчен хәбәр җөмлә
3) синтетик иярчен аергыч җөмлә
4) аналитик иярчен тәмамлык җөмлә

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Агач җимеше **белән**, адәм эше **белән**.* (Мәкаль)
1) тезүче теркәгечләр
2) иярткүче теркәгечләр
3) бәйлекләр
4) бәйлек сүзләр

9. Җөмләдәге ясалма исемне күчереп языгыз. **(2 балл)**
Иртән торып тышка чыксам, исем китте: җир шытырдап каткан, өйалды култыксалары җем-җем килә. (Ф. Яхин)
Җавап: _____

10. Җөмләдә кулланылган хәлнең төрен языгыз. **(2 балл)**
Фәһимә ул көнне безгә керде. (Л. Ихсанова)
Җавап: _____

II. Теоретик бирем.

Алынмалар турында языгыз, мисаллар китерегез. **(8 балл)**

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүзләр һәм төшеп калган хәрефләрне тәңгәлләштерегез. Артык берәмлекләр барлыгын онытмагыз. **(5 балл)**

А	тә...сир	1	ь
Ә	шагыйр...	2	ъ
Б	и...ътибар	3	г
В	...әйкәл	4	э
Г	и...тыяҗ	5	х
		6	h

Җавап:_____

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Яр куенына язгы ташудан боз кисәкләре, чыбык-чабык, салам чүпләре сыенып калган. Авыл башындагы агач күперне, һәр елдагыча, (диңгез / ташу / су) үзе белән алып киткән. Аргы якка чыгыйм дисәң, өстенә кадәр су менеп җиткән торба-басма аша тәвәккәлләргә генә кала.

Кардан арчылып кына килгән бакчаның (тәрәзәсе / капкасы / бүрәнәсе) ачык калганмы, ишек алдыннан чыгып качканмы – бүген-иртәгә бәрәнлисе олы сарыклары ниндидер могҗиза белән (бу якка / аръякка / суга) ук килеп чыккан иде. Хикмәт димә инде, шунда бәрәнләп тә куйган җитмәсә.

Кемдер күреп, хәбәр итүгә, әнисе зур кунычлы резин итекләрен киеп, өйдән чыгып та (барды / чапты / китте). Сабыйлыгы беләнме, кызык күрергә

өметләнепме, кыз да аның артыннан иярде. Әнә аның әнисе, ашыга-кабалана инеш буена йөгерә. Аръяктагы сарыкның бертуктамый ачыргаланып мәәлдәве, күз күреп ияләнгән кечкенә инешнең олы (дөньяга / дәрьяга / зурга) әйләнүе, әнкәсенең басма башында икеләнеп торуы сәбәп булдымы – кызның күңеленә кинәт кенә шом йөгерде. *(А. Әхмәтгалиева)*

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) Һәр җавапка - 0,5 балл.**

Ап-ак карга ятып бер елыйсы килә,
Күз яшьләрем туңып бозга әйләнсенгә.
Җылы өм...т итеп бер сорыйсы килә,
«Минем хәлдә инде, дөн...я <....> әллә син дә?»
Һаваларга менеп бер җырлыйсы килә,
Җанымдагы бозлар эреп түгелсен лә.
Шыксыз бу җи...анны матурлыйсы килә,
«Бөт...н дөнья назга-язга күмелсен лә» (*И. Юзеевтан*)

3. Шигырьнең беренче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

_____

4. *Җылы өм...т итеп бер сорыйсы килә, «Минем хәлдә инде, дөн...я <....>әллә син дә?»* җөмләсеннән күчерелмә мәгънәле сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)

_____

5. Беренче җөмләдән хәл фигыльләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. **(5 балл)**

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

6. Шигырьдән ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз.

(3 балл)

7. *Ап-ак карга ятып бер елыйсы килә, Күз яшьләрем туңып бозга әйләнсенгә.* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. **(2 балл)**

8.“*Игелек эшләргә һичкайчан соң түгел*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)